**ТР АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УРМАНДЕЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

№ 6

01 март 2016 ел

**Хөкем ителгәннәрнең җәзасын үтәү өчен мәҗбүри эш төрләрен һәм объектларны билгеләү турында**

РФ Җинаять кодексы нигезендә 49 статьясының 1 өлеше, 25 статьясының 1 өлеше нигезендә Урмандеево авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә хөкем ителгәннәр җәзасын үтәгәндә, шулай ук мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза билгеләнгән затларны төзәтү, аларда җәмгыять нормаларына, кагыйдәләренә, иҗтимагый-файдалы хезмәткә хөрмәтле мөнәсәбәт формалаштыру максатларында Урмандеево авыл җирлеге башкарма комитеты

Карар кабул итте:

1. Урмандев авыл җирлеге территориясе чикләрендә мәҗбүри эшләрне башкару урыннарын билгеләргә: Савгачево,Урмандеево,СидуловоЕрыклы,Сосновка,Кече Акташ,Заря авыл җирлекләрендә җинаять - башкару инспекцияләре белән килешү буенча.

2. Мәҗбүри эш төрләрен билгеләргә - торак пунктларны төзекләндерү һәм яшелләндерү, зиратларны төзекләндерү, юллар һәм буалар буендагы куакларны кисү, елгалар һәм чишмәләр территорияләрен санитар чистарту, җинаять-башкару инспекцияләре белән килешү буенча юлларны һәм башка тышкы төзекләндерү объектларын ремонтлау.

3. Әлеге карарны ФКУның Аксубай районы буенча филиалы белән берлектә төзәтү яки мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән һәм Урмандев авыл җирлеге территориясендә яшәүче затларга карата суд карарларының үтәлешен Россия Федераль җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе җинаять-башкару инспекциясе тарафыннан тәэмин итү өчен җибәрергә.

4. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштырырга: http:// aksubayevo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам..

Урмандеево авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе В.З. Николаев.

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УРМАНДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ